Л.И. Сәүбәнова Ә.С. Тайсин

ГЕОГРАФИЯ

ТЕСТЛАР

6 сыйныф

«Мәгариф» нәшрияты

Л. И. Сәүбәнова Ә. С. Тайсин

ФИЗИК ГЕОГРАФИЯ БУЕНЧА ТЕСТЛАР

Татар урта гомуми белем мәктәбенең
6 сыйныфы өчен

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә

Казан
«Мәгариф» нәшрияты
2001

УДК 373.167.1
ББК 74. 262.6я72
С93

Охраняется законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Сәүбәнова Л. И., Тайсин Ә. С.

С93 Физик география буенча тестлар: Татар урта гомуми белем мәкт. 6 с-фы өчен.— Казан: Мәгариф, 2001.— 47 б.
ISBN 5-7761-0904-3

Бу ярдәмлектә 6 сыйныф укучылары өчен «Физик география» курсы буенча тестлар тупланган. Алар һәр тема буенча укучыларның белемнәрен тикшерергә һәм курсның йомгаклау дәресләрен үткәрергә ярдәм итәчәк.

БЗ—9(68) — 55 —2002/2003

ISBN 5-7761-0904-3

© «Мәгариф» нәшрияты, 2001

ГЕОГРАФИК КАРТА ҺӘМ ГЕОГРАФИК КООРДИНАТАЛАР

1 нче вариант

1. Әгәр картаның санлы масштабы 1:30 000 булса, исемле масштаб ничек языла?

1. 1 см да 3 км.
2. 1 см да 300 м.
3. 1 см да 30 м.

2. Әгәр картада исемле масштаб «1 см да 50 км» дип күрсәтелсә, санлы масштаб ничек языла?

1. 1 : 50 000.
2. 1 : 500 000.
3. 1 : 5 000 000.

3. Географик киңлек — ул ...

1. экватордан алып бирелгән ноктага кадәр төньякка яки көньякка таба сузылган дуганың градуслар белән күрсәтелгән зурлыгы.
2. башлангыч меридианнан бирелгән ноктага кадәр көнчыгышка яки көнбатышка таба сузылган дуганың градуслар белән күрсәтелгән зурлыгы.

4. Географик озынлыкны картада яки глобуста кайсы сызык буенча билгелиләр?

1. Параллель буенча.
2. Меридиан буенча.

5. Географик координаталар һәм географик объектлар арасындагы тәңгәллекне күрсәтегез:

Географик координаталар:	Географик объектлар:
1. 28° к. к., 109° кб. оз.	А. Лондон шәһәре.
2. 38° т. к., 122° кб. оз.	Б. Кракатау вулканы.
3. 7° к. к., 105° кч. оз.	В. Пасха утравы.
4. 52° т. к., 0° оз.	Г. Сан-Франциско шәһәре.

6. Яңа Гвинея утравы Австралиядән кайсы якка таба урнашкан?

1. Көньякка.
2. Төньякка.
3. Көнбатышка.
4. Көнчыгышка.

7. Лимпопо елгасы Африканың кайсы өлешендә ага?

1. Көньяк өлешендә.
2. Төньяк өлешендә.
3. Көнбатыш өлешендә.
4. Көнчыгыш өлешендә.

8. 54° т. к., 59° кч. оз. географик координаталарына кайсы географик объект туры килә?

1. Братск шәһәре.
2. Владивосток шәһәре.
3. Магнитогорск шәһәре.

9. Кордильер тауларының уртача биеклеген ачыклагыз.

1. 1000 м дан тәбәнәгрәк.
2. 1000 м—2000 м тирәсе.
3. 2000 м дан биегрәк.

10. Түбәндә саналган диңгезләрнең кайсы тирәнрәк?

1. Кара диңгез.
2. Охота диңгезе.
3. Япон диңгезе.

2 нче вариант

1. Әгәр картаның санлы масштабы 1:2500 булса, исемле масштаб ничек языла?

1. 1 см да 25 км.
2. 1 см да 250 км.
3. 1 см да 25 м.

2. Әгәр картада исемле масштаб «1 см да 6 км» дип күрсәтелсә, санлы масштаб ничек языла?

1. 1 : 60 000.
2. 1 : 600 000.
3. 1 : 6 000 000.

3. Географик озынлык — ул ...

1. экватордан алып бирелгән ноктага кадәр төньякка яки көньякка таба сузылган дуганың градуслар белән күрсәтелгән зурлыгы.
2. башлангыч меридианнан бирелгән ноктага кадәр көнчыгышка яки көнбатышка таба сузылган дуганың градуслар белән күрсәтелгән зурлыгы.

4. Географик киңлекне картада яки глобуста нинди сызык буенча билгелиләр?

1. Меридиан буенча.
2. Параллель буенча.

5. Географик координаталар һәм географик объектлар арасындагы тәңгәллекне күрсәтегез.

Географик координаталар:	Географик объектлар:
1. 63° т. к., 152° кб. оз.	А. Виктория шарлавыгы.
2. 1° к. к., 78° кб. оз..	Б. Каһирә шәһәре.
3. 30° т. к., 32° кч. оз.	В. Котопахи вулканы.
4. 18° к. к., 26° кч. оз.	Г. Мак-Кинли тавы.

6. Утлы Җир утравы Көньяк Америкадан кайсы якка таба урнашкан?

1. Көньякка.
2. Төньякка.
3. Көнбатышка.
4. Көнчыгышка.

7. Һиндстан ярымутравы Евразиянең кайсы өлешендә урнашкан?

1. Көньяк өлешендә.
2. Төньяк өлешендә.
3. Көнбатыш өлешендә.
4. Көнчыгыш өлешендә.

8. 55° т. к., 74° кч. оз. географик координаталарына кайсы географик объект туры килә?

1. Архангельск шәһәре.
2. Омск шәһәре.
3. Магадан шәһәре.

9. Амазонка түбәнлегенең уртача биеклеген ачыклагыз.

1. 0—200 м.
2. 200—500 м.
3. 500 м дан биегрәк.

10. Түбәндә саналган диңгезләрнең кайсы тирәнрәк?

1. Балтыйк диңгезе.
2. Баренц диңгезе.
3. Каспий диңгезе.

3 нче вариант

1. Әгәр картаның санлы масштабы 1:400 000 булса, исемле масштаб күпме була?

1. 1 см да 400 м.
2. 1 см да 4 км.
3. 1 см да 40 км.

2. Әгәр картада исемле масштаб «1 см да 750 м» дип күрсәтелсә, санлы масштаб ничек языла?

1. 1:75 000.
2. 1:750 000.
3. 1:7 500 000.

3. Меридиан — ул ...

1. җир өслегендә экваторга параллель итеп шартлы рәвештә үткәрелгән сызык.
2. җир өслегендә бер географик полюстан икенчесенә кадәр шартлы рәвештә үткәрелгән иң кыска сызык.

4. Глобуста меридианнарның формасы нинди?

1. Ярымәйләнәләр.
2. Әйләнәләр.

5. Географик координаталар һәм географик объектлар арасындагы тәңгәллекне күрсәтегез.

Географик координаталар:	Географик объектлар:
1. 33° к. к., 71° кб. оз.	А. Анхель шарлавыгы.
2. 6° т. к., 62° кб. оз.	Б. Париж шәһәре.
3. 49° т. к., 2° кч. оз.	В. Кергелен утраулары.
4. 50° к. к., 69° кч. оз.	Г. Сантьяго шәһәре.

6. Шри-Ланка утравы Евразиядән кайсы якка таба урнашкан?

1. Көньякка.
2. Төньякка.
3. Көнбатышка.
4. Көнчыгышка.

7. Гурон күле Төньяк Американың кайсы өлешендә урнашкан?

1. Төньяк өлешендә.
2. Көньяк өлешендә.
3. Көнбатыш өлешендә.
4. Көнчыгыш өлешендә.

8. 63° т. к., 143° кч. оз. географик координаталарына кайсы географик объект туры килә?

1. Төмән шәһәре.
2. Чита шәһәре.
3. Оймякон шәһәре.

9. Урал тауларының уртача биеклеген ачыклагыз.

1. 500—2000 м.
2. 2000—3000 м.
3. 3000 м дан биегрәк.

10. Түбәндә саналган диңгезләрнең кайсы тирәнрәк?

1. Баренц диңгезе.
2. Ка́ра диңгезе.
3. Лаптевлар диңгезе.

4 нче вариант

1. Әгәр картаның санлы масштабы 1:1 000 000 булса, исемле масштаб ничек языла?

1. 1 см да 100 км.
2. 1 см да 10 км.
3. 1 см да 1 км.

2. Әгәр картада исемле масштаб «1 см да 2 м» дип күрсәтелсә, санлы масштаб ничек языла?

1. 1:20 000.
2. 1:2 000.
3. 1:200.

3. Параллель — ул ...

1. җир өслегендә экваторга параллель итеп шартлы рәвештә үткәрелгән сызык.
2. җир өслегендә бер географик полюстан икенчесенә кадәр шартлы рәвештә үткәрелгән иң кыска сызык.

4. Глобуста параллельләрнең формасы нинди?

1. Ярымәйләнәләр.
2. Әйләнәләр.

5. Түбәндәге географик координаталар һәм географик объектлар арасындагы тәңгәллекне күрсәтегез.

Географик координаталар:	Географик объектлар:
1. 36° т. к., 140° кч. оз.	А. Килиманджаро вулканы.
2. 3° к. к., 38° кч. оз.	Б. Токио шәһәре.
3. 20° т. к., 156° кб. оз.	В. Аконкагуа тавы.
4. 32° к. к., 70° кб.оз.	Г. Килауэа вулканы.

6. Мадагаскар утравы Африкадан кайсы якка таба урнашкан?

1. Төньяк-көнчыгышка.
2. Төньяк-көнбатышка.
3. Көньяк-көнчыгышка.
4. Көньяк-көнбатышка.

7. Анд таулары Көньяк Американың кайсы өлешендә урнашкан?

1. Төньяк өлешендә.
2. Көньяк өлешендә.
3. Көнбатыш өлешендә.
4. Көнчыгыш өлешендә.

8. 55° т. к., 56° кч. оз. географик координаталарына кайсы географик объект туры килә?

1. Воронеж шәһәре.
2. Уфа шәһәре.
3. Якутск шәһәре.

9. Урта Рус калкулыгының уртача биеклеген ачыклагыз.

1. 0—200 м.
2. 200—500 м.
3. 500 м дан биегрәк.

10. Түбәндә күрсәтелгән диңгезләрнең кайсы тирәнрәк?

1. Ак диңгез.
2. Балтыйк диңгезе.
3. Каспий диңгезе.

1 нче вариант

1. Җир кабыгының иң калын урыны кайда була?

1. Таулар астында.
2. Тигезлекләр астында.
3. Океан төпләрендә.

2. Мәрмәр, кварцит, кристаллик сланецлар, гнейс нинди тау токымнары төркеменә керә?

1. Магматик.
2. Метаморфик.
3. Утырма.

3. Ниндидер урынның географик координаталары 53—66° т. к., 65—85° кч. оз. Бу урынның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 4° т. к., 9° кч. оз. Бу — ...

1. Орисаба вулканы.
2. Кракатау вулканы.
3. Камерун вулканы.

5. Шушы материкта җир шарындагы иң биек тау түбәсе урнашкан. Ул материк — ...

1. Көньяк Америка.
2. Австралия.
3. Евразия.

2 нче вариант

1. Мантиянең уртача калынлыгы күпме?

1. 70—80 км.
2. 2900 км.
3. 3500 км.

2. Известьташ, тоз, гипс, балчыклы сланецлар нинди тау токымнары төркеменә керә?

1. Магматик.
2. Метаморфик.
3. Утырма.

3. Ниндидер урынның географик координаталары 0—8° к. к., 48—75° кб. оз. Бу урынның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 36° т. к., 138° кч. оз. Бу — ...

1. Килиманджаро вулканы.
2. Ключи Сопкасы вулканы.
3. Фуҗияма вулканы.

5. Кайсы материкта уртача абсолют биеклек 500—1000 м дан артмый, ә иң биек тау түбәсе 2228 м га гына җитә?

1. Көньяк Америка.
2. Австралия.
3. Евразия.

3 нче вариант

1. Җир кабыгының иң юка урыны кайда була?

1. Таулар астында.
2. Тигезлекләр астында.
3. Океан төпләрендә.

2. Базальт, гранит нинди тау токымнары төркеменә керә?

1. Магматик.
2. Метаморфик.
3. Утырма.

3. Ниндидер урынның географик координаталары 50—55° т. к. , 35—38° кч. оз. Бу урынның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 37° т. к. һәм 14° кч. оз. Бу — ...

1. Килиманджаро вулканы.
2. Этна вулканы.
3. Везувий вулканы.

5. Кайсы материкта иң озын тау системасы урнашкан?

1. Көньяк Америкада.
2. Австралиядә.
3. Төньяк Америкада.

4 нче вариант

1. Литосфера нәрсә ул?

1. Җир шарының җир кабыгы һәм мантиядән торган катламы.
2. Җир шарының җир кабыгы һәм мантиянең өске өлешеннән торган катламы.
3. Җир шарының мантия һәм төштән торган катламы.

2. Көчле җир тетрәүләр кайда була?

1. Кавказ тауларында.
2. Амазонка түбәнлегендә.
3. Идел буе калкулыгында.

3. Ниндидер тауларның географик координаталары 8° т. к. –50° к. к. , 65—80° кб. оз. Аларның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Тәбәнәк таулар.
2. Урта биеклектәге таулар.
3. Биек таулар.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 3° к. к. , 38° кч. оз. Бу — ...

1. Килиманджаро вулканы.
2. Ключи Сопкасы вулканы.
3. Кракатау вулканы.

5. Рельеф формалары буларак калкулыклар һәм яссы таулыклар өстенлек иткән материкны атагыз.

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Төньяк Америка.

5 нче вариант

1. Абсолют биеклеге 200 м дан 500 м га кадәр булган тигезлекләр ничек дип атала?

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

2. Убылма иңкүлекләр арасындагы калку урын ничек дип атала?

1. Калкым.
2. Убылма.

3. Ниндидер тауларның географик координаталары 52—67° т. к., 57—67° кч. оз. Аларның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Тәбәнәк таулар.
2. Урта биеклектәге таулар.
3. Биек таулар.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 41° т. к. һәм 15° кч. оз. Бу — ...

1. Килиманджаро вулканы.
2. Этна вулканы.
3. Везувий вулканы.

5. Җир шарында иң биек материкны атагыз (аның океан өсте тигезлегеннән уртача биеклеге 2000 м дан артык).

1. Африка.
2. Антарктида.
3. Төньяк Америка.

6 нчы вариант

1. Абсолют биеклеге океан өсте тигезлегеннән 500 м дан артык булган тигезлекләр ничек дип атала?

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

2. Җир кабыгында як-ягы баскычсыман булып күтәрелгән калкулар арасындагы аска иңгән өлеш ничек дип атала?

1. Калкым.
2. Убылма.

3. Ниндидер тауларның географик координаталары 28—32° т. к., 73—92° кч. оз. Аларның исемен атагыз һәм биеклеге буенча рельефның нинди формасына туры килүен әйтегез.

1. Тәбәнәк таулар.
2. Урта биеклектәге таулар.
3. Биек таулар.

4. Ниндидер вулканның географик координаталары 18° т. к., 98° кб. оз. Бу — ...

1. Орисаба вулканы.
2. Кракатау вулканы.
3. Камерун вулканы.

5. Хәзерге вакытта ата торган иң биек вулкан кайсы материкта урнашкан?

1. Көньяк Америка.
2. Австралия.
3. Евразия.

1 нче вариант

1. **Җир шарында су бетмәүгә нәрсә сәбәпче?**

1. Океаннар һәм диңгезләр булу.
2. Елгалар һәм күлләр булу.
3. Бозлыклар булу.
4. Грунт һәм җир асты сулары булу.
5. Бөтендөнья су әйләнеше булу.

2. **Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 0 м дан 200 м га кадәр була?**

1. Материк сайлыкларында (шельф).
2. Материк сөзәклекләрендә.
3. Океан казанлыкларында.
4. Желобларда.

3. **Архипелаг нәрсә ул?**

1. Коры җирнең бик зур участоклары.
2. Коры җирнең зур булмаган участогы.
3. Утраулар төркеме.

4. **Океан агымнары барлыкка килүгә төп сәбәпче булып нәрсә санала?**

1. Географик киңлекләр.
2. Суны кояш нурларының җылытуы.
3. Даими җилләр.

5. **Яр буйлары дүрт океан суы белән юыла торган материкның исемен атагыз.**

1. Евразия.
2. Африка.
3. Төньяк Америка.
4. Көньяк Америка.
5. Антарктида.
6. Австралия.

6. **Океан белән тоташа торган диңгезләр арасында иң җылы һәм тозлы (42‰) диңгез — ...**

1. Кариб диңгезе. 2. Көньяк-Кытай диңгезе. 3. Кызыл диңгез.

2 нче вариант

1. Гидросфера нәрсә ул?

1. Җирнең каты таш сүрүе.
2. Җирнең су сүрүе.
3. Җирнең һава сүрүе.

2. Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 6000 — 7000 м дан артыграк?

1. Материк сайлыкларында.
2. Материк сөзәклекләрендә.
3. Океан казанлыкларында.
4. Желобларда.

3. Диңгез нәрсә ул?

1. Океанның бер өлеше, ләкин аннан суы, агымнары, анда яшәүче тереклек ияләренең үзенчәлекләре белән аерыла.
2. Океанның бер өлеше, киң булмаган су киңлеге, ул ике яктан да материк ярлары яки утраулар белән чикләнә.

4. Диңгездә (океанда) су күтәрелеше барлыкка килүнең төп сәбәпчесе булып нәрсә санала?

1. Океан агымнары.
2. Айның суларны тартуы.
3. Даими җилләр.

5. Иң салкын һәм мәйданы буенча иң кечкенә океанның исемен атагыз.

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Төньяк Боз океаны.
4. Һинд океаны.

6. Өч дөнья кисәгенең яр буйларын юа торган диңгез — ... .

1. Беринг диңгезе.
2. Урта диңгез.
3. Кызыл диңгез.

3 нче вариант

1. **Дөньяда су әйләнешенең иң төп сәбәбе нәрсәдә?**

1. Салкын һәм җылы агымнар.
2. Җирнең эчке җылылыгы.
3. Кояш энергиясе.

2. **Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 2000—3000 м дан артык?**

1. Материк сайлыкларында.
2. Материк сөзәклекләрендә.
3. Океан казанлыкларында.
4. Желобларда.

3. **Материк нәрсә ул?**

1. Коры җирнең бик зур участоклары.
2. Коры җирнең зур булмаган участогы.
3. Утраулар төркеме.

4. **Цунами барлыкка килүнең сәбәбе нәрсәдә?**

1. Диңгез төбендә җир тетрәү.
2. Даими җилләр.
3. Океан агымнары.

5. **Иң җылы һәм мәйданы буенча иң зур океанның исемен атагыз.**

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Төньяк Боз океаны.
4. Һинд океаны.

6. **Бер үк вакытта ике диңгез һәм ике океанны тоташтыра, ә ике материкны һәм ике дәүләтне аера торган бугаз — ...**

1. Беринг бугазы.
2. Гибралтар бугазы.
3. Дрейк бугазы.

4 нче вариант

1. Дөнья океаны дигән төшенчәгә нинди сулыклар керә?

1. Елгалар, күлләр, сазлыклар, бозлыклар, җир асты сулары.
2. Диңгезләр, океаннар, култыклар, бугазлар.
3. Газ, боз, су.

2. Океан төбенең кайсы өлешендә тирәнлек 200 м дан 2 000 м га кадәр була?

1. Материк сайлыкларында.
2. Материк сөзәклекләрендә.
3. Океан казанлыкларында.
4. Желобларда.

3. Утрау нәрсә ул?

1. Коры җирнең бик зур участогы.
2. Коры җирнең зур булмаган участогы.
3. Утраулар төркеме.

4. Физик карталарда океан төбе ничек күрсәтелә?

1. Горизонтальләр белән.
2. Зәңгәр төсне катламлап буяу, изобаталар һәм тирәнлекне күрсәтүче саннар белән.

5. Барлык меридианнар да кисеп чыга торган океан — ... .

1. Тын океан.
2. Атлантик океан.
3. Төньяк Боз океаны.
4. Һинд океаны.

6. Иң тар бугаз — ...

1. Магеллан бугазы.
2. Гибралтар бугазы.
3. Босфор бугазы.

1 нче вариант

1. «Эчке җир өсте сулары» дигән төшенчәгә нинди сулыклар керә?

1. Океаннар, диңгезләр, култыклар, бугазлар.
2. Елгалар, күлләр, сазлыклар, җир асты сулары, бозлыклар.
3. Газ, су, боз.

2. Җир асты грунт суларына нинди үзенчәлекләр хас?

1. Су үткәрмәүчән катламнар аста гына була һәм аларга бер генә су йөртүчән катлам туры килә.

2. Су үткәрмәүчән катламнар аста да, өстә дә бар, аларга берничә су йөртүчән катлам туры килә.

3. Елгаларның кайсылары Төньяк Боз океаны бассейнына керә?

1. Сырдәрья, Терек, Кура.
2. Печора, Енисей, Лена.
3. Дунай, Днепр, Дон.

4. 57° т. к., 33° кч. оз. географик координаталары кайсы елганың башланган урынын күрсәтә?

1. Идел.
2. Ангара.
3. Амур.
4. Миссисипи.

5. Җир шарында иң озын елга — ...

1. Амазонка. 2. Нил. 3. Янцзы.

6. Рәсемдә «А» хәрефе белән елга үзәне профиленең кайсы өлеше күрсәтелгән?

1. Елга юлы.
2. Тугай.
3. Елга террасасы.



Рәс. 1.

7. Күбесенчә кар сулары белән туена торган елга кайчан ташый?

1. Яз көне. 2. Җәй көне. 3. Көз көне.

8. Азиядә тирәнлеге һәм мәйданы буенча иң зур күл. Бу күлдә Россиядәге төче суларның 80% ы, ә дөнья төче суларының 20% ы тупланган. Бу күлнең исеме — ...

1. Ханка. 2. Таймыр. 3. Байкал.

2 нче вариант

1. Кайсы диаграмма җирдәге суларның чагыштырмача күләмен билгели?

1. 2. 3.



Дөнья океаны сулары — Атмосфера һәм коры җир сулары

2. Катламара җир асты суларына нинди үзенчәлекләр хас?

1. Су үткәрмәүчән катламнар аста гына ята һәм аларга бер генә су йөртүчән катлам туры килә.

2. Су үткәрмәүчән катламнар аста да, өстә дә бар, аларга берничә су йөртүчән катлам туры килә.

3. Елгаларның кайсылары Тын океан бассейнына керә?

1. Дунай, Нил, Конго.
2. Амур, Хуанхэ, Колорадо.
3. Ганг, Тигр, Замбези.

4. 29° т. к., 89° кб. оз. географик координаталары кайсы елга тамагын күрсәтә?

1. Идел. 3. Амур.
2. Амазонка. 4. Миссисипи.

5. Җир шарында иң биек шарлавык кайсы елга бассейнында урнашкан?

1. Ориноко. 2. Замбези. 3. Конго.

6. Әгәр елга үзәне тар һәм тирән булса, ә елга юлы артык борылмалы булмыйча, үзәннең бөтен төбен алып торса, бу елга — ...

1. Тигезлек елгасы.
2. Тау елгасы.

7. Күбесенчә боз сулары белән туена торган елга кайчан ташый?

1. Яз көне. 2. Җәй көне. 3. Көз көне.

8. Җир шарында мәйданы буенча иң зур күл — ...

1. Виктория күле.
2. Югары күл.
3. Каспий диңгезе.

3 нче вариант

1. Бөтендөнья су әйләнеше — ул өзлексез процесс. Аның схемасы түбәндәгечә:

1. Океан → атмосфера → океан.
2. Океан → атмосфера → коры җир → океан.

2. Татарстан Республикасында җир асты грунт суларының биеклеге кайсы сезонда иң югары була?

1. Яз көне. 2. Җәй көне. 3. Көз көне.

3. Елгаларның кайсылары Атлантик океан бассейнына керә?

1. Сырдәрья, Терек, Кура.
2. Миссисипи, Нил, Дунай.
3. Печора, Енисей, Лена.

4. 31° т. к., 79° кч. оз. географик координаталары кайсы елганың башланган урынын күрсәтә?

1. Идел.
2. Амазонка.
3. Днепр.
4. Ганг.

5. Җир шарында иң тулы сулы елга — ...

1. Амазонка.
2. Нил.
3. Янцзы.

6. Рәсемдә В хәрефе белән елга үзәне профиленең кайсы өлеше күрсәтелгән?

1. Елга юлы.
2. Тугай.
3. Елга террасасы.



Рәс. 2

7. Әгәр елга үзәне киң һәм елга юлы борылмалы булса, бу елга — ...

1. Тигезлек елгасы.
2. Тау елгасы.

8. Әлеге диңгезнең (күлнең) яр буйлары— коры җирдә иң түбән урын, ә суларының тозлылыгы уртача 270‰ гә тигез (максималь тозлылыгы— 310‰.) Бу — ...

1. Каспий диңгезе.
2. Арал диңгезе.
3. Үле диңгез.

4 нче вариант

1. Табигатьтә кече су әйләнеше процессы кайсы схема буенча бара?

1. Океан → атмосфера → океан.
2. Океан → атмосфера → коры җир → океан.

2. Җәй көне җир асты суларының температурасы җир өсте сулары белән чагыштырганда ...

1. югарырак.
2. бертигез.
3. түбәнрәк.

3. Түбәндә күрсәтелгән елгаларның кайсылары Һинд океаны бассейнына керә?

1. Амур, Хуанхэ, Колорадо.
2. Дунай, Днепр, Дон.
3. Ганг, Тигр, Замбези.

4. 6° к. к., 13° кч. оз. географик координаталары кайсы елга тамагын күрсәтә?

1. Һинд.
2 Конго.
3. Хуанхэ.
4. Енисей.

5. Татарстан Республикасындагы барлык елгалар нинди бассейнга керә?

1. Төньяк Боз океаны бассейнына.
2. Атлантик океан бассейнына.
3. Каспий диңгезе бассейнына
4. Эчке су агышы бассейнына.

6. Рәсемдә С хәрефе белән елга үзәне профиленең кайсы өлеше күрсәтелгән?

1. Елга юлы.
2. Тугай.
3. Елга террасасы.



Рәс. 3

7. Тигезлек елгаларының агым тизлеге тау елгалары белән чагыштырганда ...

1. тизрәк.
2. бертигез.
3. әкренрәк.

8. Агымлы күл агымсыз күлдән нәрсә белән аерыла?

1. Барлыкка килүе белән.
2. Мәйданы белән.
3. Даими рәвештә су алмашыну белән.

1 нче вариант

1. Һаваның барлык массасының 80% ы диярлек атмосфераның шушы катлавында тупланган, азот һәм кислород газларына бай, монда һава торышының үзгәрү процесслары бара, бер километр өскә күтәрелгән саен, температура уртача 6°С ка салкыная. Бу — ...

1. Тропосфера.
2. Стратосфера.
3. Атмосфераның өске катламнары.

2. Җил тизлеген кайсы прибор ярдәмендә үлчиләр?

1. Гигрометр.
2. Анемометр.
3. Осадкомер.

3. Тауның итәгендә атмосфера басымы 735 мм т. б. күрсәтә. Тауның чагыштырмача биеклеге 4735,5 м булса, тау түбәсендә атмосфера басымы күпмегә тигез булыр?

1. 315 мм т. б..
2. 284 мм т. б..
3. 250 мм т. б..

4. Гыйнварның уртача айлык температурасы $t_г = -13°C$, ә июльнеке $t_и = 20°C$ булганда Казан шәһәрендә һава температурасы тирбәлешенең еллык амплитудасы ...

1. 7°С.
2. 20°С.
3. 33°С.

5. Кышкы муссон кайсы юнәлештә исә?

1. Материктан океанга таба.
2. Океаннан материкка таба.

6. Рәсемдә күрсәтелгән һава хәрәкәте — ...

1. Көндезге бриз.
2. Төнге бриз.



Рәс. 4.

7. 2 км дан 8 км га кадәрле биеклектә барлыкка килә торган болытларны атагыз.

1. Катламлы болытлар.
2. Өем болытлар.
3. Каурыйсыман болытлар.

8. Җир өстендәге үсемлекләр, төрле корылмалар һәм башкаларның суынган өслекләрендә тупланучы дымга туенган һава явым-төшемнең нинди төрен барлыкка китерә?

1. Чык.
2. Чык, бәс, сыкы.
3. Чык, бәс һәм яңгыр.

9. Кайсы җылылык поясында елның дүрт фасылы да күзәтелә?

1. Тропик.
2. Уртача.
3. Поляр.

10. Төньяк ярымшарда 22 июнь көненә түбәндә күрсәтелгән үзенчәлекләрнең кайсылары хас?

1. Азрак яктыртылган, көн төннән кыскарак, поляр түгәрәкләр белән чикләнгән өлешендә поляр төннәр хөкем сөрә.

2. Күбрәк яктыртылган, көн төннән озынрак, поляр түгәрәкләр белән чикләнгән өлешендә поляр көннәр күзәтелә.

2 нче вариант

1. Атмосфераның бу катламына түбәндәге үзенчәлекләр хас: бу катламның өске чиге 50—55 км биеклектә, һава сирәгәйгән була, өскә күтәрелгән саен температура да арта, су парлары бөтенләй юк диярлек. Бу — ...

1. Тропосфера.
2. Стратосфера.
3. Атмосфераның өске катламлары.

2. Һаваның дымлылыгын кайсы прибор ярдәмендә үлчиләр?

1. Гигрометр.
2. Анемометр.
3. Осадкомер.

3. Тауның түбәсендә һава температурасы −12°С. Тауның чагыштырмача биеклеге 5500 м булса, аның итәгендә һава температурасы күпмегә тигез?

1. 45°С.
2. 15°С.
3. 21°С.

4. Ел әйләнешендә Мәскәүдә уртача һава температурасы $t_г = -10°C$, $t_ф = -9°C$, $t_м = -4°C$, $t_а = 5°C$, $t_м = 13°C$, $t_и = 16°C$, $t_и = 18°C$, $t_а = 17°C$, $t_с = 11°C$, $t_о = 5°C$, $t_н = -2°C$, $t_д = -8°C$ булганда, уртача еллык һава температурасын исәпләп чыгарыгыз.

1. 4,3°С.
2. 1,2°С.
3. 9,8°С.

5. Җәйге муссон кайсы юнәлештә исә?

1. Материктан океанга таба.
2. Океаннан материкка таба.

6. Рәсемдә күрсәтелгән һава хәрәкәте — ...

1. Көндезге бриз.
2. Төнге бриз.



Рәс. 5

7. 2 км биеклеккә кадәр барлыкка килә торган болытларны атагыз.

1. Катламлы болытлар.
2. Өем болытлар.
3. Каурыйсыман болытлар.

8. Түбәндә күрсәтелгән явым-төшемнәрнең кайсылары болытлардан ява?

1. Кар гына.
2. Кар, яңгыр һәм боз.
3. Кар, яңгыр һәм чык.

9. Нинди җылылык поясында ел буена эссе климат күзәтелә?

1. Тропик.
2. Уртача.
3. Поляр.

10. Кайсы ярымшарда 22 декабрьдән җәй башлана?

1. Төньяк ярымшарда.
2. Көньяк ярымшарда.

3 нче вариант

1. Тропосфераның максималь калынлыгы нинди киңлекләрдә күзәтелә?

1. Экваторда.
2. Уртача киңлекләрдә.
3. Поляр киңлекләрдә.

2. Атмосфера басымын кайсы прибор ярдәмендә үлчиләр?

1. Термометр.
2. Барометр-анероид.
3. Флюгер.

3. Тауның итәгендә атмосфера басымы 723 мм т. б. күрсәтә. Тауның түбәсендә басым 315 мм т. б. булса, тауның чагыштырмача биеклеге якынча күпмегә тигез?

1. 4284 м. 2. 2335 м. 3. 7128 м.

4. Һаваның температурасы 0°С ка, ә чагыштырмача дымлылыгы 80% ка (температурасы 0°С тигез булган вакытта 1 м³ туенган һавада 5 г су бар) тигез булса, 1 м³ һавада ничә грамм су булыр?

1. 1 грамм су.
2. 4 грамм су.
3. 2 грамм су.

5. Түбәндәге картосхемада уклар белән нинди җилнең юнәлеше күрсәтелгән?

1. Кышкы муссонның.
2. Җәйге муссонның.

6. Көндезге бриз нинди юнәлештә исә?

1. Күл өстеннән (елгадан) коры җиргә таба.
2. Коры җирдән күл өстенә (елгага) таба.

7. 8 км дан 18 км га кадәрле биеклектә барлыкка килә торган болытларны атагыз.

1. Катламлы болытлар.
2. Өем болытлар.
3. Каурыйсыман болытлар.

8. Су парларыннан су тамчылары барлыкка килсен өчен нинди шарт кирәк?

1. Һава җылынырга тиеш.
2. Һава суынырга тиеш.

9. Нинди җылылык поясы чикләрендә ел буена салкын климат күзәтелә?

1. Тропик.
2. Уртача.
3. Поляр.

10. Кайсы ярымшарда 22 июньнән кыш башлана?

1. Төньяк ярымшарда.
2. Көньяк ярымшарда.

4 нче вариант

1. Атмосфераның минималь калынлыгы нинди киңлекләрдә күзәтелә?

1. Экваторда.
2. Уртача киңлекләрдә.
3. Поляр киңлекләрдә.

2. Җилнең юнәлешен кайсы прибор ярдәмендә билгеләрләр?

1. Гигрометр.
2. Барометр-анероид.
3. Флюгер.

3. Тауның итәгендә һава температурасы 24°C. Тауның түбәсендә температура −15°C булса, тауның чагыштырмача биеклеге якынча күпмегә тигез?

1. 5000 м.
2. 6500 м.
3. 3200 м.

4. Ел әйләнешендә Казанда уртача һава температурасы $t_г = -13^\circ C$, $t_ф = -12{,}1^\circ C$, $t_м = -6{,}3^\circ C$, $t_а = 3{,}9^\circ C$, $t_м = 13^\circ C$, $t_и = 17{,}6^\circ C$, $t_и = 20^\circ C$, $t_а = 17{,}6^\circ C$, $t_с = 11{,}3^\circ C$, $t_о = 3{,}8^\circ C$, $t_в = -3{,}8^\circ C$, $t_д = -10{,}6^\circ C$ булганда Казан шәһәренең уртача еллык һава температурасын исәпләп чыгарыгыз.

1. 5,2°С
2. –2 С.
3. 3,3°С.

5. Түбәндәге картосхемада уклар белән нинди җилнең юнәлеше күрсәтелгән?

1. Кышкы муссонның.
2. Җәйге муссонның.

6. Төнге бриз нинди юнәлештә исә?

1. Күл өстеннән (елгадан) коры җиргә таба.
2. Коры җирдән күл өстенә (елгага) таба.

7. Коеп ява торган яңгыр кайсы төр болытлардан барлыкка килә?

1. Катламлы болытлардан.
2. Өем болытлардан.
3. Каурыйсыман болытлардан.

8. Һаваның юнәлеше ничек үзгәргәндә, анда булган су парлары су тамчыларына әйләнә?

1. Һава өскә күтәрелгәндә.
2. Һава аска төшкәндә.

9. Татарстан Республикасы территориясенә нинди типтагы климат хас?

1. Диңгез.
2. Уртача континенталь.
3. Кискен континенталь.
4. Муссонлы.

10. Төньяк ярымшарда 22 декабрь көненә түбәндә күрсәтелгән үзенчәлекләрнең кайсылары туры килә?

1. Азрак яктыртылган, көн төннән кыскарак, поляр түгәрәкләр белән чикләнгән өлешендә поляр төннәр хөкем сөрә.
2. Күбрәк яктыртылган, көн төннән озынрак, поляр түгәрәкләр белән чикләнгән өлешендә поляр көннәр күзәтелә.

1 нче вариант

1. Җир шарында кеше иң күп яши торган материк — ...

1. Евразия.
2. Африка.
3. Төньяк Америка.
4. Көньяк Америка.
5. Антарктида.
6. Австралия.

2. Түбәндәге билгеләрнең кайсы раса вәкилләренә хас икәнен дөрес сайлап җавап бирегез: тәннәре ак яки каракучкыл, чәчләре аксыл яки кара; коңгырт-кара күзләрдән башлап зәңгәр күзләргә кадәр төрле төстәге күзләр хас; яңак сөяге алга чыгып тормый, борыннары тар, иреннәре нечкә яки уртача калынлыкта.

1. Европеоид раса.
2. Монголоид раса.
3. Экваториаль раса.

3. Түбәндәге дәүләтләргә аларның башкалаларын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Дәүләтләр:

1. Япония.
2. Берләшкән Гарәп Әмирлекләре (БГӘ)
3. Кения.
4. Колумбия.

Башкалалар:

А. Найроби.
Б. Богота.
В. Токио.
Г. Абу-Даби.

4. Җир шарында мәйданы буенча иң зур ил — ...

1. Канада. 2. Кытай. 3. Россия Федерациясе.

5. Бу ил Атлантик океанның көнбатышында Антиль утрауларының берсендә урнашкан. Башкаласының географик координаталары: 23,5° т. к., 82° кб. оз. Бу ил — ...

1. Ямайка. 2. Куба. 3. Мексика.

2 нче вариант

1. Җир шарында кеше иң аз яши торган материк — ...

1. Евразия.
2. Африка.
3. Төньяк Америка.
4. Көньяк Америка.
5. Антарктида.
6. Австралия.

2. Түбәндәге билгеләрнең кайсы раса вәкилләренә хас икәнен дөрес сайлап җавап бирегез: тәннәре карасу, чәчләре кара һәм бөдрә, күзләре коңгырт-кара; башка раса вәкилләре белән чагыштырганда алар калын иренле һәм киң борынлы.

1. Европеоид раса.
2. Монголоид раса.
3. Экваториаль раса.

3. Түбәндәге дәүләтләргә аларның башкалаларын тәңгәл китереп җавап бирегез.

Дәүләтләр:	*Башкалалар:*
1. Камерун.	А. Сантьяго.
2. Монголия.	Б. Минск.
3. Беларусь.	В. Яунда.
4. Чили.	Г. Улан-Батор.

4. Җир шарында халык саны буенча иң зур дәүләт — ...

1. Канада.
2. Кытай.
3. Россия Федерациясе.

5. Бу ил Африканың төньяк өлешендә урнашкан. Кайчандыр аның территориясендә борынгы Карфаген дәүләте урнашкан булган. Ул — көнбатышта Алжир, көньяк-көнчыгышта Ливия илләре белән чикләшә, ә аның төньяк һәм көнчыгыш чикләрен Урта диңгез сулары юа. Башкаласының географик координаталары: 33° т. к., 13,5° кч. оз.. Бу ил — ...

1. Мисыр.
2. Тунис.
3. Марокко.

3 нче вариант

1. Кайсы материкта дәүләтләр юк?

1. Евразия.
2. Африка.
3. Төньяк Америка.
4. Көньяк Америка.
5. Антарктида.
6. Австралия.

2. Җир шарында иң күп санлы раса — ул — ...

1. Европеоид раса.
2. Монголоид раса.
3. Экваториаль раса.

3. Түбәндәге дәүләтләргә аларның башкалаларын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Дәүләтләр:	*Башкалалар:*
1. Мадагаскар.	А. Белград.
2. Югославия.	Б. Астана.
3. Аргентина.	В. Антананариву.
4. Казахстан.	Г. Буэнос-Айрес.

4. Җир шарында халык саны буенча иң зур шәһәр — ...

1. Нью-Йорк.
2. Мехико.
3. Шанхай.

5. Бу ил Евразия материгының көньяк өлешендә урнашкан һәм территориясендә 4000 еллар элек борынгы цивилизацияләр булуы билгеле. Илнең хәзерге башкаласы — җир шарындагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе, аның географик координаталары: 28° т. к., 78° кч. оз. Бу ил — ...

1. Пакистан.
2. Һиндстан.
3. Непал.

4 нче вариант

1. Бу материкның халкы күп гасырлар буе коллар чыганагы булган. Бу материк — ...

1. Евразия.
2. Африка.
3. Төньяк Америка.
4. Көньяк Америка.
5. Антарктида.
6. Австралия.

2. Түбәндәге билгеләрнең кайсы раса вәкилләренә хас икәнен дөрес сайлап җавап бирегез: тәннәре сары, күзләре кысынкы, чәчләре туры кара һәм яңак сөяге чыгып тора.

1. Европеоид раса.
2. Монголоид раса.
3. Экваториаль раса.

3. Түбәндәге дәүләтләргә аларның башкалаларын тәңгәл китереп җавап бирегез:

Дәүләтләр:	*Башкалалар:*
1. АКШ (Америка Кушма Штатлары).	А. Дүшәнбе.
2. Австралия.	Б. Вашингтон.
3. Төркия.	В. Канберра.
4. Таҗикстан.	Г. Анкара.

4. Бу шәһәрдә дөньяның иң зур мәйданы булып саналган Тяньаньмынь мәйданы урнашкан. Бу шәһәр — ...

1. Токио. 2. Пхеньян. 3. Пекин.

5. Бу ил Африка материгының төньяк-көнчыгышында урнашкан. 3000—4000 еллар элек бу ил территориясендә урнашкан борынгы цивилизация безгә үзенең гаять зур пирамидалары белән таныш. Илнең хәзерге башкаласының географик координаталары 30,5° т. к., 31° кч. оз.. Бу ил — ...

1. Мисыр.
2. Эфиопия.
3. Судан.

«ФИЗИК ГЕОГРАФИЯ» КУРСЫ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ ТЕСТЫ

1 нче вариант

1. Җир шарында 6 нчы материкның ачылуы кайсы сәяхәтченең исеме белән бәйле?

1. Ф. Магеллан.
2. Дж. Кук.
3. Ф. Ф. Беллинсгаузен һәм М. П. Лазарев.

2. Түбәндә бирелгән санлы масштабка исемле масштабны тәңгәл китереп җавап бирегез.

Санлы масштаб:	*Исемле масштаб:*
1. 1 : 10 000 000.	А. 1 см да 1 км.
2. 1 : 100 000.	Б. 1 см да 10 м.
3. 1 : 1000	В. 1 см да 100 км.

3. Түбәндәге географик координаталарда урнашкан шәһәрләрнең баш хәрефләре җавапта бирелгән бер шәһәрнең исемен тәшкил итә. Россиянең физик картасын кулланып, бу шәһәрнең исемен атагыз.

1. 63° т. к., 142,5° кч. оз.
2. 59,5° т. к., 151° кч. оз.
3. 66,5° т. к., 67° кч. оз.
4. 56° т. к., 49° кч. оз.

1. Орел. 2. Омск. 3. Орск.

4. Еш кабатлана торган көчле җир тетрәүләр кайда була?

1. Кавказ тауларында.
2. Урал тауларында.
3. Көнбатыш Себер тигезлегендә.

5. Түбәндәге җавапта күрсәтелгән тау токымнарының берсеннән башкасы утырма тау токымнарына керә. Бу үзгә тау токымы ...

1. Известьташ.
2. Ком.
3. Гранит.
4. Балчык.

6. Океан агымнары барлыкка килүнең төп сәбәпчесе нәрсә?

1. Географик киңлек.
2. Суны кояш нурларының җылытуы.
3. Даими җилләр.

7. Әгәр дә елга бассейнында явым-төшемнәрнең ел әйләнәсендәге бүленеше графикта күрсәтелгәнчә булса, бу елгада су ташу елның кайсы вакытында күзәтелә?

1. Кыш көне.
2. Яз көне.
3. Җәй көне.
4. Көз көне.



8. Кышкы муссон кайсы юнәлештә исә?

1. Океаннан материкка таба.
2. Материктан океанга таба.

9. Гыйнварның уртача айлык температурасы $t_г = -10{,}2°C$, июльнеке $t_и = +18{,}1°C$ булганда, Мәскәү шәһәрендә һава температурасы тирбәлешенең еллык амплитудасы күпме була?

1. 28,3°С. 2. 38,4°С. 3. 7,9°С.

10. Түбәндәге илләр арасыннан коры җир чикләре булмаган дәүләтне сайлап алыгыз.

1. Франция.
2. Япония.
3. Россия Федерациясе.

2 нче вариант

1. Дөнья тирәли беренче сәяхәтне оештыручының исемен атагыз.

1. Христофор Колумб.
2. Фернан Магеллан.
3. Марко Поло.

2. Гренландия утравы Төньяк Америка материгыннан кайсы якка таба урнашкан?

1. Төньяк-көнчыгышка.
2. Төньяк-көнбатышка.
3. Көньяк-көнчыгышка.
4. Көньяк-көнбатышка.

3. Түбәндәге географик координаталарда урнашкан шәһәрләрнең баш хәрефләре җавапта бирелгән бер шәһәрнең исемен тәшкил итә. Җир шарының сәяси картасын кулланып, бу шәһәрнең: а) исемен табыгыз, б) кайсы ил башкаласы икәнен билгеләгез.

1. 1° т. к., 104° кч. оз.
2. 18° к. к., 48° кч. оз.
3. 13° т. к., 15° кч. оз.
4. 5° т. к., 1,5° кб. оз.

1. Осло. 2. Санс. 3. Сана.

4. Абсолют биеклеге буенча Көнбатыш Себер тигезлеге — ...

1. Түбәнлек.
2. Калкулык.
3. Яссы таулык.

5. Түбәндәге җавапта күрсәтелгән тау токымнарының берсеннән башкасы — метаморфик тау токымнарына керә. Бу үзгә тау токымы — ...

1. Гнейс.
2. Комташ.
3. Мәрмәр.
4. Кварцит.

6. Кайсы океан яр буйларында «цунами» дигән табигый күренеш ешрак күзәтелә?

1. Төньяк Боз океаны.
2. Тын океан.
3. Балтыйк диңгезе.

7. Әгәр дә елга бассейнында явым-төшемнәрнең ел әйләнәсендәге бүленеше рәсемдә күрсәтелгәнчә булса, бу елгада су ташу елның кайсы вакытында күзәтелә?

1. Кыш көне.
2. Яз көне.
3. Җәй көне.
4. Көз көне.



8. Җәйге муссон кайсы юнәлештә исә?

1. Океаннан материкка таба.
2. Материктан океанга таба.

9. Ел әйләнешендә торак пунктның уртача айлык һава температуралары: $t_{г}$ = 25,9°C, $t_{ф}$ = 25,4°C, $t_{м}$ = 26,7°C, $t_{а}$ = 27,6°C, $t_{м}$ = 27,5°C, $t_{нв}$ = 27,0°C, $t_{ил}$ = 27,0°C, $t_{а}$ = 269°C, $t_{с}$ = 27°C, t_{0} = 26,6°C, $t_{н}$ = 26,4°C, $t_{д}$ = 26,0°C булганда, уртача еллык һава температурасын исәпләп чыгарыгыз һәм дөрес җавапны табыгыз.

1. 25,4°C. 2. 26,66°C. 3. 25,82°C.

10. Түбәндәге илләр арасыннан диңгез чикләре булмаган дәүләтне сайлап алыгыз.

1. Һиндстан.
2. Испания.
3. Монголия.

3 нче вариант

1. Һиндстанны беренчеләрдән булып барып күргән рус сәяхәтчесе — ...

1. Марко Поло.
2. Афанасий Никитин.
3. М. П. Лазарев.

2. Татарстан Республикасының территориясе Көнчыгыш Европа тигезлегенең кайсы өлешендә урнашкан?

1. Төньяк өлешендә.
2. Көньяк өлешендә.
3. Көнчыгыш өлешендә.
4. Көнбатыш өлешендә.

3. Түбәндәге географик координатларда урнашкан шәһәрләрнең баш хәрефләре җавапта бирелгән бер шәһәрнең исемен тәшкил итә. Россиянең физик картасын кулланып, бу шәһәрнең исемен атагыз.

1. 55° т.к., 62° кч.оз., 3. 55° т.к., 124,5° кч.оз.,
2. 67,5° т.к., 87° кч.оз., 4. 64,5° т.к., 41,5° кч.оз..

1. Чижа. 2. Чита. 3. Омск.

4. Өстенлек итүче абсолют биеклеге буенча Урал таулары — ...

1. Түбән таулар.
2. Урта биеклектәге таулар.
3. Биек таулар.

5. Түбәндәге җавапта күрсәтелгән тау токымнарының берсеннән калганы — магматик тау токымнарына керә. Бу үзгә тау токымы ...

1. Пемза. 3. Балчык.
2. Гранит. 4. Базальт.

6. Ни өчен җир шарында су бетми?

1. Океаннар һәм диңгезләр булганга.
2. Елгалар һәм күлләр булганга.
3. Бозлыклар булганга.
4. Табигатьтә су әйләнеше булганга.
5. Туфрак һәм җир асты сулары булганга.

7. Әгәр елга күбрәк кар сулары белән туенса, ул кайчан ташый?

1. Кыш көне. 3. Җәй көне.
2. Яз көне. 4. Көз көне.

8. Җирдә климатның күптөрлелегенең төп сәбәбе — ...

1. Тропосфераның калынлыгы төрлечә булу.
2. Төрле географик киңлекләрдә кояш нурлары төшү почмагы бертөрле булмау.
3. Җирдә атмосфера басымы поясларының төрлечә булуы.

9. Гыйнварның уртача айлык температурасы $t_г = -27,4$ °C, ә июльнеке $t_и = +18,7$ °C булганда Чита шәһәрендә һава температурасы тирбәлешенең еллык амплитудасы күпме була?

1. 45,1 °C. 2. 46,1 °C. 3. 8,7 °C.

10. Дәүләтләр саны буенча беренче урында торучы материк — ...

1. Евразия.
2. Төньяк Америка.
3. Көньяк Америка.

4 нче вариант

1. Дөньяның географик картасын беренчеләрдән булып төзегән галим — ...

1. Птолемей. 2. М. Бехайм. 3. Х. Колумб.

2. Физик география картасы ярдәмендә нәрсәләр турында белеп була?

1. Авыл яки шәһәрнең мәйданы турында.
2. Төрле объектларның географик координаталары турында.
3. Урманлы урыннар һәм далаларның кайда урнашулары турында.

3. Түбәндәге географик координатларда урнашкан шәһәрләрнең баш хәрефләре җавапта бирелгән бер урынның исемен тәшкил итә. Җир шарының сәяси картасын кулланып, бу географик объектның исемен атагыз.

1. 28° т. к., 87° кч. оз.,
2. 38° т. к., 40° кч. оз.,
3. 43° т. к., 79° кб. оз.,
4. 32,5° к. к., 70° кб. оз.

А. Ганг елгасының чыганагы.
Б. Этна вулканы.
В. Каһирә шәһәре.

4. Татарстан җирлегендә өстенлек итүче рельеф формасы — ...

1. Яссы тигезлек.
2. Калкулы тигезлек.
3. Түбән таулар.

5. Татарстан җирлегендә өстенлек итүче казылма байлыклар — ...

1. Магматик токымнар ясалышына керә.
2. Метаморфик токымнар ясалышына керә.
3. Утырма токымнар ясалышына керә.

6. Россия территориясендәге елгаларның күбесе ...

1. Төньяк Боз океаны бассейнына керә.
2. Атлантик океан бассейнына керә.
3. Тын океан бассейнына керә.

7. Байкал күле казанлыгы ясалуның төп сәбәбе — ...

1. Калкым барлыкка килү.
2. Убылма барлыкка килү.
3. Җир катламының баскыч кебек ярылып аска төшүе.

8. Кайсы яктыртылу поясында төшке кояшны кешеләр елына ике тапкыр зенитта күрәләр?

1. Поляр пояста.
2. Уртача пояста.
3. Тропик пояста.

9. Мәсьәләне чишегез һәм дөрес җавапны сайлап алыгыз: тау итәкләрендә $t = +16°C$, ә тау түбәсендә $-14\ °C$ булса, таулардагы кар сызыгы чиге якынча кайсы биеклектән башлана?

1. Якынча 2000 м биеклектән.
2. Якынча 3000 м биеклектән.
3. Якынча 4500 м биеклектән.

10. Дәүләтләр саны буенча иң соңгы урында торучы материк — ...

1. Африка.
2. Австралия.
3. Төньяк Америка.



Номенклатурадагы географик объектларны картада шартлы билгеләр яки саннар белән күрсәтегез.



6 НЧЫ СЫЙНЫФ КУРСЫ БУЕНЧА ГЕОГРАФИК НОМЕНКЛАТУРАНЫ БЕЛҮ ДӘРӘҖӘСЕН ТИКШЕРҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

1 нче вариант

Кавказ таулары
Амазонка түбәнлеге
Җомолунгма тавы
Миссисипи елгасы
Енисей елгасы
Каспий диңгезе
Кариб диңгезе
Ботник култыгы
Мадагаскар утравы
Гавай утраулары
Һиндстан ярымутравы

2 нче вариант

Анд таулары
Ключи Сопкасы вулканы
Коммунизм пигы
Колорадо елгасы
Ангара елгасы
Байкал күле
Урта диңгез
Япон диңгезе
Фин култыгы
Гренландия утравы
Алеут утраулары

3 нче вариант

Урал таулары
Везувий вулканы
Амазонка елгасы
Нигер елгасы
Амур елгасы
Арал диңгезе
Гарәп диңгезе
Гудзон култыгы
Калимантан утравы
Зур Антил утраулары
Һиндкытай ярымутравы

4 нче вариант

Памир таулыгы
Котопахи вулканы
Маккензи елгасы
Замбези елгасы
Хуанхэ елгасы
Эйр күле
Кызыл диңгез
Мексика култыгы
Баффин Җире утравы
Курил утраулары
Лабрадор ярымутравы

5 нче вариант

Һималай таулары
Этна вулканы
Миссури елгасы
Парана елгасы
Янцзы елгасы
Ладога күле
Балтыйк диңгезе
Бискайя култыгы
Яңа Гвинея утравы
Төньяк Җир архипелагы
Флорида ярымутравы

6 нчы вариант

Кордильер таулары
Кракатау вулканы
Конго елгасы
Обь елгасы
Евфрат елгасы
Үле диңгез
Көньяк Кытай диңгезе
Бенгалия култыгы
Тасмания утравы
Яңа Җир утравы
Азов диңгезе

7 нче вариант

Альп таулары
Орисаба вулканы
Укаяли елгасы
Нил елгасы
Анхель шарлавыгы
Онега күле
Ка́ра диңгезе
Зур Австралия култыгы
Сахалин утравы
Яңа Себер утраулары
Сомали ярымутравы

8 нче вариант

Алтай таулары
Килиманджаро вулканы
Ганг елгасы
Днепр елгасы
Ниагара шарлавыгы
Чад күле
Баренц диңгезе
Беринг бугазы
Суматра утравы
Врангель утравы
Тянь-Шань таулары

9 нчы вариант

Саян таулары
Эльбрус тавы
Һинд елгасы
Урал елгасы
Виктория шарлавыгы
Мичиган күле
Лаптевлар диңгезе
Гибралтар бугазы
Утлы Җир утравы
Камчатка ярымутравы
Филиппин утраулары

10 нчы вариант

Көнчыгыш-Европа тигезлеге
Мак-Кинли тавы
Килауэа вулканы
Тигр елгасы
Амудәрья елгасы
Югары күл
Танганьика күле
Чукот диңгезе
Магеллан бугазы
Бөек Британия утравы
Таймыр ярымутравы

11 нчы вариант

Көнбатыш Себер тигезлеге
Аконкагуа тавы
Дунай елгасы
Лена елгасы
Виктория күле
Гурон күле
Көнчыгыш Себер диңгезе
Дрейк бугазы
Шри-Ланка утравы
Ява утравы
Гарәп ярымутравы

12 нче вариант

Урта Себер яссы таулыгы
Фуҗияма вулканы
Идел елгасы
Иртыш елгасы
Сырдәрья елгасы
Ньяса күле
Кара диңгез
Охота диңгезе
Босфор бугазы
Яңа Зеландия утравы
Скандинавия ярымутравы

Учебное издание

Саубанова Лилия Ильгизовна
Тайсин Анвар Сафович

ТЕСТЫ
ПО ФИЗИЧЕСКОЙ ГЕОГРАФИИ

Для 6 класса татарской средней общеобразовательной школы

(на татарском языке)

Редакторы *Р. С. Вафина*
Бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Тышлык рәссамы *Ю. А. Щетинина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Р. М. Галимова*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, А. А. Дәүләтова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 31.09.2001. Форматы 60×90$^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 3,0.
Нәшер-хисап табагы 1,24. Тиражы 6 200 д. Заказ Ч-60.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.

ГУП ПИК «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

ISBN 5-7761-0904-3